Галимҗанова, Р.  Кешеләрдә болан язмышы / Р. Галимҗанова // Идел. – 2023. – №4 (403). – Б. 34-37.



Рәфидә ГАЛИМҖАНОВА


# Кешеләрдә – «БОЛАН» язмышы

**Февраль аенда Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры беренче тапкыр Казанга зур гастроль белән килде. Камал театры сәхнәсендә алар тарафыннан өч спектакль – «Яшь йөрәкләр» (Фәтхи Бурнаш), «Капка» (Айгөл Әхмәтгалиева) һәм «Болан» (Аяз Гыйләҗев) куелды. Сезгә тәкъдим итәсе язмамда мин Аяз Гыйләҗевнең «Баласын җуйган болан эзеннән» әсәренә нигезләнгән «Болан» спектакленә тукталырмын.**

## «УСАЛЛЫК» БИТЛЕГЕ

Яшьлектә кылган зур хаталар өчен үкенеп яшәүнең мәгънәсе бармы? Ә җан тынычлык тапсын өчен нишләргә? Кеше гомере буе шушы сорауларга җавап эзләп яши. Кемдер үткәннәре белән көрәшә, ә кайберәүләр алардан ераккарак кача. Нәкъ менә Рәхимҗан кебек.

Әсәрнең төп герое – Рәхимҗан. Аны Татарстанның атказанган артисты Рафил Сәгъдуллин уйный. Спектакль башланганчы үзе белән сөйләшеп алдык, роле турында: «Усал булса да, яратам шул Рәхимҗанымны!» – дип тәмләп сөйләп, кызыктырып куйган иде. Тизрәк шул усал ир-атның ниләр майтарганын беләсе килде (алдан ук әйтәм – бу әсәрне укыганым юк иде). Ә Рәхимҗан, чыннан да, тормышында зур








хаталар кылырга өлгергән. Без аны беренче күренештә иң элек «ике хатын белән торучы» усал ир буларак күрәбез. Бер карасаң, исеменә җисеме туры килми кебек. Үзе – Рәхимҗан, ә үзе рәхимсез, шәфкатьсез. Шуңа күрә аннан бөтен кеше курка. Хәтта шул куркуыннан бауга менүче дә була... Шул дәрәҗәдә куркыныч булырлык нәрсә эшләгән соң ул Рәхимҗан? Бу сорауга җавап, аның сукыр хатыны Мәсрүрә җырында аңлашыла:

*– Урманнарда йөрдем бер ялгызым,*
*Баласын җуйган болан эзеннән...*

Бу юлларны ишеткәч, Рәхимҗанның күңеле йомшара. Әмма алай да «усаллык» битлеген салмый. Эчтәлекне аңлавы җиңеләя төшә – димәк, аның бәхетсезлегенең сәбәбе үткәннәргә – яшьлек хаталарына барып тоташа. Хатыны әйтмешли, «яшьлектә хаталар кылмасаң иде лә ул!» Мәсрүрә ролен чын-чынлап ышандырып уйнаган Миләүшә Имамовага тукталасым

**СЮЖЕТ ЛИНИЯСЕ БУЛГАН БОЛАН БЕЗНЕ СПЕКТАКЛЬ АХЫРЫНА КАДӘР ОЗАТА БАРА. ЛӘКИН КЕМ ЯКИ НӘРСӘ СОҢ УЛ БОЛАН? УЛ МАХСУС СИМВОЛИК МӘГЪНӘДӘ КУЛЛАНЫЛГАН КЕБЕК.**






Фотолар театр архивыннан

килә. Ул - шундый нәфис, сылу, бер карашка фәрештә булып күренә. Күлмәге дә ап-ак, күңеле сыман саф кебек. Әмма сукыр. Аңа бу хакта янәшәдәгеләре еш искә төшереп тора, әйтерсең лә, үзенең сукыр икәнен белми...Тик күзе күрмәсә дә, башкалар күрә алмаганны күңеле белән тоя ала. Ул йомшак тавышы, җиңел хәрәкәтләре белән үзенә карата. Әмма аның да үткәннәре бик бәхетле булмаган - иң элек мәхәббәттән сукыраеп шушы хәлгә калган икән лә. Шунда гына Рәхимҗанның ник ике хатын белән яшәве ачыклана.

## «ИР ТҮГЕЛ, Ә ХЫЯЛ!»

Рәхимҗанның усаллыгын аклый торган бер нәрсә бар - ул үзенең сүзен әйтә ала торган горур ир-ат! Үзе әйтмешли, «башкалар йомшак булганга усал» ул! Бу җөмләдән соң мин аның тискәрелеген дә, шундый булуын да ошата башладым! Хәзерге заманда хатыны сүзеннән чыга алмаган ир-атлар күп - ул шуңа борчыла. Бу проблеманы күрсәтү өчен әсәрдә Тәминдар Рәхимов (Рәзил Фәхертдинов) бар. Соңрак без аның Рәхимҗанның улы икәнен беләбез. Ул - хатынына бер кәлимә сүз әйтергә курыккан «хатынша» ир. Идәнен дә юа, ашарга да пешерә, хатыны ни куша - шуны эшләп кенә тора, тик үз фикерен әйтә алмый. Туган ягын ташлап киткәннән бирле шундый яшәү рәвеше алып бара, әмма болай яшәү аңа ошап бетми. Гаиләдә баш та буласы килә бит, сүзенең дә үтемле булуын тели. Әмма кырыс әйтергә тырышкан җөмләләре үтемле яңгырамый. Хатыны Зәлия (Чулпан Арсланова), русча әйткәндә, «женщина - огонь»! Бизәнгән-ясалган, тормышы мул - ашарына пешкән, киеме үтүкләнгән, ике баласын караучы ире бар. Үзе әйтмешли, «ир түгел, ә хыял!» Ләкин бу хыялдагы ир белән ерак китеп булмый. Балалары да ерак китә алмаган әнә: кызлары -уйлары белән башка дөньяда очып йөрүче Азия (Диләрә Сөләйманова), ә уллары (анысы ярыйсы әле) этиләреннән гарьләнеп өйдән качарга теләүче Гайрәт (Эдуард Латыйпов). Мин башта «Тәминдар боларның үз аталарымы соң?» дип утырдым. Бөтенләй дә охшамаган! Гайрәттә, атасыннан аермалы буларак, ир-атка хас сыйфатлар бар. Шуңа да ата белән ул бер- берсен аңламый. Тегесенең улына сүзе үтми, ә улы, шул сүзне үтемле итеп әйтә белмәгәнгә, атасын сүгә.
- Ичмаса, ачулана да белмисең бит син! - дип әрни чыгып киткәндә.
Иң сәере - балалар әти-әниләренә «Рәхимов - Рәхимова» дип эндәшә. «Әтием», «әнием» дигән сүзләр бу гаиләдә кулланылмый. Алар өчен усал Рәхимова һәм аның сүзеннән чыкмаучы Рәхимов кына бар. Бу урында тагын авыр булып куйды: киләчәктә гаиләдә ата-анага фамилия белән генә эндәшүгә калсак, нәрсә көтәргә? Безнең өчен бу



куркыныч төш булса, Рәхимовлар гаиләсе өчен гадәти күренеш.

## СЕРЛЕ БОЛАН

Сюжет линиясе булган Болан безне спектакль ахырына кадәр озата бара. Ләкин кем яки нәрсә соң ул Болан? Ул махсус символик мәгънәдә кулланылган кебек. Мәсәлән, мин аны ир-атларның «боланлану»ы итеп кабул иттем. Аннары эчтәлек белән танышкан саен баласыз калган боланның нинди хәлдә булуын күзалладым. Тәминдар да бит ата назын күрми үскән, шуңа артык «сылу, йомшак». Әмма Рәхимҗан да рәхәттә яшәмәгән, баласын гомере буе уйлаган, аның киләчәге өчен борчылгандыр. Болан - үзе нәфис, әмма мөгезле җан иясе - Рәхимҗан белән Тәминдар кебек.



Яшьлегендә баласын җуйган Рәхимҗан туган йортына кайткан улын күрмәгәнгә салыша. Аны ын ир булмавына ачулана:
- Телең, иманың, нәсел дәвамчың юк икән, нигә яшәргә?! Хатын колы! – ди ул аның турында.
Әмма бөтенләй өметне өзәргә иртәрәк – Тәминдар улы Гайрәт бабасы эзеннән барырга карар кыла, ягъни аңа нәкъ менә Рәхимҗан янында булу ошый. (Бу урында нәсел дәвамчысы бар икән әле дип сөендем.)
Әмма Азия кызларын «тотып кыйныйсы килә», валлаһи! Ул миңа чит сериалларын карап, кумирлары белән шашкан кыз булып күренде.
һәм бөтен характерын күңелсез булганда сөйләгән сүзе ачып салды:
- Үзгәртәм – динемне дә, исемемне дә, телемне дә, хәтта җенесемне дә! – ди ул урманда югалган сукыр Мәсрүрәне эзләгәндә. Бу җөмлә – җөмлә генә түгел. Бу – Аяз абыйның тирән фәлсәфәсе, борчуы, киләчәк буын өчен кайгыруы кебек яңгырады. Хәер, Тәминдар белән Зәлиядән нинди тәрбияле кеше туа алсын инде?!
- Мин Азия булмыйм! Мин – Офелия! Мин – Диана! Юк, Мин Николай булам. Мин кияүгә чыкмыйм, мин – өйләнәм!
Бу сүзләрне ул яңа танышкан Тәбрискә (Фердинант Насретдинов) сөйли. Анысы да Рәхимҗан кебек кенә егет. Шул сыйфаты өчен Азия аны ошата да («егет түгел, ә хыял!» – ди әнисе кебек). Болар бергә калса, тагын бер Рәхимовлар барлыкка килә диган сүз...

## ТАБИГАТЬТӘ – БЕЗНЕҢ ЧАГЫЛЫШ

Миңа сәхнәдәге декорацияләр ошады! Өй – күзге формасында ясалган, ә Болан өстән төшерелгән пәрдә аша күрсәтелде. Ул бер яктан төш тә, икенче яктан психологик халәт кебек кабул ителде. Күзге дә юкка гына кулланылмагандыр, Рәхимҗан – урманчы, аның бөтен белгәне – урман. Оныгы Азия: «Боларны тамырдан кисеп атарга да, асфальт салырга кирәк!» – дип тора. «Сезнең кулга калса, салырсыз да», – дип җавап бирә ул аңа. Әмма урманны ташлап китәргә җыенмый. Ул аның тормыш күзгесе.

## КУРКЫНЫЧ ТӨШ ТӘМАМ. КҮЗНЕ АЧКАЧ НИ БУЛЫР?

Спектакльне караганда куркыныч төш күргәндәй булдым. Башта кайсы проблеманы беренче планга чыгарырга белми утырдым. Алар барысы да актуаль һәм әһәмиятле кебек. Хәер, һәр тамашачы үзенә кирәген, күңеле борчыганын алгандыр бу спектакльдән. Мин анда 18 яшьлек сеңлем белән барган идем. Кайтканда фикерләре турында сораштым:
– Мин Азиянең Тәбрискә бик тиз ризалашуына аптырадым. Ул да бит аның әтисе кебек җебегән егет! Шундый ук гаилә булып яшәрләрмени соң? – диде ул. Мин моңа сөендем. Димәк, ул үзенә киләчәккә, спектакль мисалында, дәрес ала алган. Мин дә үзем өчен файдалы сабак алдым: гомерең үкенечле булмасын дисәң, яшьлектә хаталарны ясама икән ул! Такташ әйтмешли, гомере бик кыска бит аның...

